| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

31.03.2020 г.Лениногорск № 41

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Мөэмин-Каратай» АГРСтан югары басым үткәрүче газ» линияле объектын төзү өчен территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү

Халыкның муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын үтәү, җир кишәрлекләре хокук ияләренең уңай тормыш шартларын, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст., 46 ст., «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1 «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 18 февралендәге 170 номерлы карары нигезендә әзерләнгән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Мөэмин-Каратай " АГРСтан югары басым үткәрүче газ " линияле объект төзү өчен территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне

межалау проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрү башлануы турында хәбәр итәргә.

2. 2020 елның 06 апреленнән 06 маена кадәр Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Мөэмин-Каратай» АГРСтан югары басым үткәрүче газ төзү өчен территорияне планлаштыру проектын һәм аның составындагы территорияне ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3.«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында 2020 елның 06 апреленнән аның составындагы территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты экспозициясен түбәндәге адреслар буенча ачарга:

Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар ур., 31Б йорт.

Проект экспозициясе белән танышу вакыты дүшәмбедән җомгага

9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр һәм 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект турында консультация бирүне оештырырга.

4. 2020 елның 6 апреленә кадәр территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын түбәндәге рәсми: http://Leninogorsk.tatarstan.ru «Шәһәр төзелеше. Планлаштыру проектлары" сайтта урнаштырырга.

5. Гавами тыңлауларда катнашучыларга планлаштыру проектына һәм аның составындагы межалау проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен түбәндәге адрес буенча «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы исеменә язма рәвештә кертергә тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар ур., 31Б йорт, электрон рәвештә: Mukkar.Len@tatar.ru - 2020 елның 6 апреленнән 6 маена кадәр яисә ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында телдән.

6. Ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын 2020 елның 6 маена 15.00 сәгатькә авыл мәдәният йортында түбәндәге адрес:Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар ур., 31Б йорты буенча билгеләргә.

7. 2020 елның 06 апреленә кадәр Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында, «Лениногорские вести» газетасында һәм түбәндәге адреслар: Мөэмин-Каратай авылы,Механизаторлары урамы, 31Б йорт буенча мәгълүмат стендларында ачык тыңлаулар башлануы турында әлеге хәбәрне бастырып чыгарырга.

8.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше башлыгы В. Н. Маркеловага йөкләргә.

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы С. В. Тимаков

В.Н. Маркелова
5-28-28